ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КЕРЛИГАЧСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КИРЛЕГӘЧ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

КАРАР

2021 елның 27 сентябре

№ 21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Кирлегәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 24 декабрендәге 3номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Кирлегәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу" муниципаль хезмәт күрсәтү регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы " Кирлегәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 17 декабрендәге 22 номерлы карарының преамбула өлешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Кирлегәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 24 декабрендәге 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Кирлегәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу" муниципаль хезмәт күрсәтү регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре»;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Кирлегәч авылы, авыл мәдәният йорты - Советская 33А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
“Кирлегәч авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы ______________ С.Р.Сәлахова

ИНН 1649012995
КПП 164901001